СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеҗе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**28 сентябрь 2018** **№ 68**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 67 номерлы "Референдум үткәрүне оештыру турында" карары нигезендә Сеҗе авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Сеҗе авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда, Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлек территориясен төзекләндерү буенча:

- Югары Масра авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен материаллар сатып алу (3 чират);
- Гөберчәк авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм материаллар сатып алу;
- Курса-Почмак,Гөберчәк авылларында чик буе аншлаглары әзерләү һәм урнаштыру;
- Ташкичү авылында Кесмә елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын ремонтлау һәм материаллар сатып алу (2 этап);
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляциялəнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәрү җайланмалары сатып алу һәм урнаштыру;

- Сикертән, Курса-Почмак, Иске Муй авылларында кече архитектура формалары сатып алу һәм балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;
- Гөберчәк авылында чишмәне төзекләндерү, материаллар сатып алу

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге
юл-урам челтәрендәге вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау.:
- Сеҗе авылы, Школьная ур., 11 йорт 12 йорт, 1до, 2 йорт, Вахитов ур., 9 йорт, 16 йорт;
- Ташкичү авылы, Такташ ур., 9дан 15кә кадәр
- Мөрәле авылы, Центральная урамы, 67дән 72гәчә (2 этап), Үзәк урамы, 33тән 34кә кадәр, Үзәк урамы, 6дан 9га кадәр;Күпер урамы, 13тән 14кә кадәр.
- Курса-Почмак авылы, Үзәк урамы, 14тән 17гә кадәр, Овражная урамы киселеше 150м;
- Иске Масра авылы, Киров ур., 1дән 1а кадәр, 22додан 23кә кадәр, 1 Май ур., 7дән 9га кадәр
- Гөберчәк авылы, М. Мәһдиев ур., 97дән., 100 йорт, 80дән 87 йортка кадәр(2 этап);
- Казаклар авылы, Ю. Гагарин ур., 19 йорттан 20кә кадәр;
- разъезд Курса авылы, Мәктәп ур., 19 йорт, тимер юл ур., 19 йорт, 23 йорт.
- Починок-Поник поселогында Кесмә елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу;

- Яңа Чүриле авылында мәктәп һәм Сергин урамнары арасында тимер-бетон боҗралар урнаштырылган дамба урнаштыру (2 этап);

3.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

- Мөрәле, Курса-Почмак, Сикертән авыллары өчен янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (һәр торак пунктка берәр).

4.Күмү урыннарын карап тоту

-- Мөрәле, Яңа Чүриле, Курса разъезды, Югары Масра, Иске Муй,Казаклар авыллары зиратлары өчен мәгълүмат стендлары әзерләү;

- Сеҗе авылы зираты территориясендә материаллар сатып алу һәм инвентарь саклау өчен бина урнаштыру;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　юк

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, КурсаПочмак авылы, Мәктәп ур., 1йорт.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　Гибадуллина Г.М.

СОВЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "СИЗИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1051689013331 ИНН 1609012692